# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Вахитов авыл җирлеге Советы

Жину бистэсе № 133 02.07. 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел № 116 карарына үзгәрешләр кертү турында(14.08.2015 елның 144 номерлы, 28.10.2018 елның 10 номерлы, 27.04.2018 елның № 89 номерлы, 13.11.2018 ел 113 номерлы, 19.12.2018 елның 118 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 24.11.2014 ел № 116 карарына үзгәрешләр кертү турында(14.08.2015 елның 144номерлы, 28.10.2018 елның 10 номерлы, 27.04.2018 елның № 89 номерлы, 13.11.2018 ел 113 номерлы, 19.12.2018 елның 118 номерлы карарлар редакциясендә) 15.04.2008 елдагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезедә

Вахитов авыл Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина - урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым

ташламаларын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә пунктчаларда күрсәтелгән затларның бер категориясенә керә торган салым түләүче булса 2, 3, 10, 10.1, 12, 15 Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пункты нигезендә һәм салым ташламасына хокукы булган салым органына салым ташламасын бирү турында гариза тапшырмаган яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән, салым ташламасы салым органы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә алынган белешмәләр нигезендә бирелә.

Салым ташламасы бирелә торган салым түләүче тарафыннан салым органына тапшырыла торган сайлап алынган салым объектлары турында хәбәрнамә үзенең теләге белән салым чоры булып торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче сайлап алынган салым ташламасы салым салу объекты турында хәбәрнамәне тапшырмаган очракта салым ташламасы һәр төр салым салуның иң чик исәпләнгән суммасы белән бер объектына карата тапшырыла.».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел № 116 карарына үзгәрешләр кертү турында(14.08.2015 елның 144номерлы, 28.10.2018 елның 10 номерлы, 27.04.2018 елның № 89 номерлы, 13.11.2018 ел 113 номерлы, 19.12.2018 елның 118 номерлы карарлар редакциясендә)3.2 пункты 2018 елның салым чорыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип бтлгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.Б.Бухарова